ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 октябрь 2017 ел № 6347

Башкарма комитетның аерым
карарларын гамәлдән чыгару турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.20 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет карарларын гамәлдән чыгарырга:

1) «Законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5897 номерлы;

2) «Балигъ булмаган зат(лар) исеменнән өстенлекле сатып алу хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5903 номерлы;

3) «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардагы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5906 номерлы.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин